Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 13-31 номерлы карары

**Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ Казан шәһәрендә яшәүчеләр турында**

Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ Казан шәһәрендә яшәүчеләрнең торак шартларын яхшырту максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы «2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында”гы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар турында»гы карарын үтәү йөзеннән Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ Казан шәһәрендә яшәүчеләрнең өстәмә исемлеген (кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
13-31 номерлы карарына
кушымта

**Социаль ипотека программасы буенча**
**торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ**
**Казан шәһәрендә яшәүчеләрнең өстәмә исемлеге**

| **№ т/б** | **Фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Гаилә составы** | **Торак комиссиясенең кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тануга дәгъва кылучылар исемлегенә кертү турындагы карары датасы** | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тимонина Юлия Анатольевна | 4 | 18.07.2024 | Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 18 августындагы 4662 номерлы карары белән расланган Гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану тәртибе һәм шартларының 3.1 пункты (янгын нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр) |
| 2 | Шакиров Руслан Марат улы | 1 | 18.07.2024 | Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 18 августындагы 4662 номерлы карары белән расланган Гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану тәртибе һәм шартларының 3.3 пункты (2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен җибәрелгән зат) |
| **Барлыгы:<br>2 гариза бирүче** | | | | |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**